**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

04.10.2018 996-п

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасы) санитар саклык зонасы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына 2017 елның 20 апрелендәге ТАТ ЗЛД 01737 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарындагы территориаль бүлегенең 2016 елның 20 июлендәге №16.20.01.000.Т.000003.07.16 дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Зеленодольск районының «Норлат ТКХ КҖП» ҖЧҖ тарафыннан тәкъдим ителгән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Норлат торак пунктында эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасының) санитар саклык зонасы проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасының) санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-

көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасының) санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә әлеге су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат ТКХ КҖП» МУП эксплуатацияли торган Норлат торак пунктындагы («РЭС» су алу корылмасы) эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре, су алу җайланмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрне хуҗалык өчен куллану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
04.10.2018 ел. № 996-п
боерыгына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасы) санитар саклык зонасы чикләре**

Татарстан Республикасы Зеленодольск районының «Норлат ТКХ КҖП» МУПның «РЭС» су алу корылмасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының көньяк-көнчыгыш өлешендә, Норлат торак пунктында, Әрә елгасының  (Зөя елгасының сул кушылдыгы) уң яр буенда урнашкан.

120 номерлы су алу корылмасының географик координаталары: $55^{0}36'8,8''$т.к., $48^{0}17'11,2''$ к.оз.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

<u>Санитар саклык зонасының I поясы</u>

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат торак пунктындагы 120 нче номерлы су алу скважинасының санитар саклык зонасының беренче поясы чикләре скважина тамагыннан 30 м ераклыкта билгеләнә:

| Скважинадан санитар саклык зонасының беренче поясына кадәрге аралык, юнәлешләр буенча, м | | | |
|---|---|---|---|
| С-В | Ю-В | Ю-З | С-З |
| 30 | 30 | 30 | 30 |

<u>Санитар саклык зонасының II поясы</u>

Әлеге скважинаның санитар саклык зонасындагы икенче поясының чиге аның тамагыннан 58 м радиус белән билгеләнә.

<u>Санитар саклык зонасының III поясы</u>

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында  «Норлат ТКХ КҖП» МУП эксплуатацияли торган «РЭС» су алу корылмасының санитар саклык зонасының өченче поясының  радиусы 413 метрга тигез.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
04.10.2018 ел. № 996-п
боерыгына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының («РЭС» су алу корылмасының) санитар саклык зонасында территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш бинарлары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

<u>«ҖИР АСТЫ СУЛАРЫ РЕСУРСЛАРЫ» ҖЧҖ</u>
420059, ТР, Казан ш., Оренбург тракты, 20 й., оф.311, 313
ИНН 1624012810/КПП 162401001, ОГРН 1111690018076
тел.843-567-50-15 e-mail ozpv116@mail.ru


РАСЛЫЙМ»

Норлат торак-коммуналь хуҗалыгы
күптармаклы җитештерү
предприятиесе» МУП директоры
Р.Р.Бәхтияров

«__»______________2015 ел.

# Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Норлат торак пунктында («РЭС» су алу корылмасы ) хуҗалык-көнкүреш һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы ПРОЕКТЫ

Башк. Усманова Н.Н.

«Җир асты сулары ресурслары» ҖЧҖ
директоры С.И.Поляков

2015 ел

# ЭЧТӘЛЕК

| Текст | | Бит. |
|---|---|---|
| | Кереш | 3 |
| 1. | Су белән тәэмин итү чыганагы турында гомуми мәгълүмат | 5 |
| 2. | Районның кыска геологик-гидрогеологик характеристикасы | 5 |
| 3. | Су алу корылмасына һәм продуктив сулык горизонтына характеристика | 13 |
| 4. | ССЗ пояслары чикләрен гидрогеологик нигезләү | 16 |
| 5. | Җир асты суларының сыйфатын тасвирлау | 24 |
| 6. | ССЗ пояслары чикләре чикләрендә санитар хәл характеристикасы | 24 |
| 7. | ССЗның беренче, икенче һәм өченче пояслары чикләренә керә торган территорияләрне хуҗалык белән файдалану кагыйдәләре һәм режимы | 31 |
| | Файдаланган әдәбият исемлеге | 42 |

## Иллюстрацияләр һәм таблицалар исемлеге

### а) Иллюстрацияләр

| № рәс. | Рәсем исеме | Бит |
|---|---|---|
| 1 | Районның картасы | 6 |
| 2 | Схематик геологик-гидрогеологик карта | 9 |
| 3 | I-I линиясе буенча схематик геологик-гидрогеологик киселеш | 10 |
| 4 | Су алу скважинасының геологик-техник киселеше һәм конструкциясе | 15 |
| 5 | №120 (РЭС) скважинасы һәм ССЗ өченче поясының чикләре урнашу схемасы | 19 |
| 6 | ССЗ су алу скважинасының беренче поясын проектлауның план-схемасы | 23 |
| 7 | Норлат торак пунктында №120 (РЭС) су алу корылмасы | 26 |
| 8 | РЭС №120 скважинасы тамагы | 26 |
| 8а,8б | ССЗның беренче поясы территориясе | 27 |
| 9 | ССЗ икенче поясы чиген урнаштыруның ситуация планы | 29 |
| 10 | ССЗның икенче һәм өченче пояслары чикләрен урнаштыруның ситуация планы | 30 |

### б) Таблицалар

| №табл. | Таблица исеме | Бит |
|---|---|---|
| 1 | Су алу скважинасы буенча төп мәгълүматлар | 14 |

### Кушымталар

| | | |
|---|---|---|
| 1 | ССЗ территориясенең санитар торышын яхшырту һәм су белән тәэмин итү чыганагының пычрануын кисәтү чаралары планы | 36 |
| 2 | 2015 елның 17 ноябрендәге 24623 номерлы лаборатория тикшеренүләре беркетмәсе | 39 |

# КЕРЕШ

Су алу корылмасының санитар саклау зоналарын (ССЗ) оештыру - хуҗалык-көнкүреш һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган җир асты суларын пычратудан саклау буенча төп чараларның берсе.

Җир асты суларының су алу корылмасы тирәсендә пычрануын булдырмас өчен, 3 поястан торган санитар саклау зонасы төзелә, аларның һәркайсында су йөртү катламына пычрану мөмкинлеген булдырмый торган махсус чаралар башкарыла.

Әлеге «ТР Зеленодольск районының Норлат торак пунктында («РЭС» су алукорылмасы) хуҗалык-көнкүреш һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклау зонасы проекты» СанПиН 2.1.4.1110-02 «Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларын һәм суүткәргечләрне санитар саклау зоналары» таләпләре нигезендә «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» һәм «Җир асты байлыклары турында» РФ законнарын үтәү йөзеннән эшләнгән.

- ССЗның беренче, икенче һәм өченче пояслары чикләрен билгеләү норматив документлар нигезендә башкарыла:
- «Су белән тәэмин итү һәм эчәргә яраклы суүткәргечләр чыганакларын санитар саклау зоналары». Санитар кагыйдәләр һәм нормалар 2.1.4.1110-02, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт санэпиднадзорының федераль үзәге, М., 2002 ел.
- «Хуҗалык-көнкүреш һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларын санитар саклау зоналарының икенче һәм өченче пояслары чикләрен гидрогеологик исәпләүләр буенча тәкъдимнәр», ВНИИ «ВОДГЕО», М, 1983 ел.

ССЗда режим булдыруның һәм тәэмин итүнең төп максаты - су белән тәэмин итү чыганакларын һәм суүткәргеч корылмаларны, шулай ук алар урнашкан территорияләрне пычранудан саклау.

ССЗ составына өч пояс керә: беренче пояс - катгый режим поясы, икенче һәм өченче пояс - чикләүләр поясы.

***Беренче пояс*** суалгычларның, барлык суүткәргеч корылмаларның һәм суүткәргеч каналның урнашу мәйданнарын үз эченә ала. Ул су алу һәм су үткәрү корылмалары урнашкан урындагы чыганакның суның очраклы яки алдан ниятләп пычрануы мөмкинлеген бетерү максатларында билгеләнә.

***ССЗның икенче поясы*** су йөртүчән офыкны микроблар пычрануыннан саклау өчен билгеләнгән. ССЗның икенче поясы чикләреннән су алу коймасына кадәр араны

билгеләүче төп параметр булып Тл исәп-хисап вакыты тора, җир асты сулары агымы белән микроб пычрануның җир асты суларын су алу корылмасына таба этәрүе тора, ул патоген организмнарның тереклек сәләтен һәм вирулентлыгын югалту өчен җитәрлек булырга тиеш.

***ССЗның өченче поясы*** җир асты суларын химик пычранудан саклау өчен билгеләнгән. ССЗ  өченче поясының чикләре аермасы шартлардан чыгып билгеләнә: әгәр аннан читтә су йөртүчән катламга химик пычранулар килсә, алар су алу корылмасына барып җитмәячәк. Җир асты суларын су алу корылмаларын проектлаганда шартлыча кабул итәләр: су йөртүчән катламга кергән химик матдәләр тотрыклы, ягъни үз составын үзгәртми һәм җир асты сулары һәм токымнары белән үзара бәйләнеш  нәтиҗәсендә туплана.

## 1. Су белән тәэмин итү чыганагы турында гомуми мәгълүмат

Җир асты суларының су алу корылмасы Әрә елгасы үзәненең уң як битендә (Зөя елгасының сул кушылдыгы), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының көньяк-көнчыгыш өлешендә, Норлат торак пунктында урнашкан (1 нче рәсем).

Бер скважинадан торган су алу корылмасы елына 39,055 мең $м^3$ (тәүлегенә 107 $м^3$) җитештерүчәнлек белән файдаланыла.

## 2. Районның су алу корылмасы чикләрендә кыска геологик-гидрогеологик характеристикасы

Тәкъдим ителә торган район (җир асты байлыклары кишәрлеге һәм аңа якын урнашкан территория 2-2,5 км радиуста) Идел алды төбәгенең төньяк өлешендә, Зөя елгасы бассейнында урнашкан.

Геологик-структур яктан караганда, карала торган район Казан-Кажим бөгелешенең көньяк-көнбатыш бортын катлауландыра торган Ассель террасы чикләрендә урнашкан.

Участок Булатка елгасының уңъяк исемсез кушылдыгы үзәненең сулъяк сөзәклегендә (Әрә елгасының уң кушылдыгы) урнашкан. Рельефның максималь абсолют билгеләре субүләргә туры килә һәм 180м га җитә, минималь (56,9м) Әрә елгасы кисешкән җиргә туры килә.

Тикшерелә торган районда төче җир асты сулары геологик кисешнең өске өлеше Казан һәм Уржум ярусларының урта Пермь терригенлы терриген-карбонат һәм карбонат-терриген ятмалары, северодвинск ярусының өске Пермь карбонат-терриген ятмаларыннан төзелгән.

Урта Пермьнең Казан ярусы түбән һәм югары подъярус утырмаларыннан гыйбарәт. Бу катламнар киң таралган; сакмара ярусының түбән Пермь катламнарының карстланган өслегендә ге ятмалар һәм терриген-карбонат токымнары белән тәкъдим ителгән.

Немдин свитасы белән тәкъдим ителгән түбән Казан подъярусының өлешләре күбесенчә известьташлар һәм мергельләр, балчык һәм гипслар катламы булган доломитлардан гыйбарәт. Балчыклар сирәк очрый, аларның калынлыгы 1,7м дан артмый. Катлам куәте 65 м га җитә.




Масштабы 1:100 000

**1 нче рәсем. Район картасы**

*Шартлы билгеләр:*

скв.120 (РЭС)

су алу корылмасы скважинасы, номеры

Югары Казан катламнары карала торган территориядән читтәге өслеккә чыга. Аларның түбәсе +50+35м тамгасында урнашкан.

Югары Казан подъярусы ятмалары өчен доломитларның, ачык көрән балчыкларның, ачык соры известьташларның, мергельләрнең ритмик катламланулары хас. Ятмаларның гомуми катламы 56-60 метр тәшкил итә. Токымнар төрле дәрәҗәдә гипс белән капланган. Гипс катлам һәм оячыклар рәвешендә.

Уржум ярусы ятмалары елга үзәннәре һәм яссы субүләр ясыйлар.

30-80 м Уржум катламнары балчык катламнары, комлы ташларны, алевролитларны доломитлар, мергельләр, известьташлар, конгломератлар, гипс катламнары белән алмашып бара.

Слобода свитасы ясалмалары тәкъдим иткән Югары Пермь ярусы котельник сериясе утырмаларында Уржум горизонты формаларында киң таралган юылганлык билгеләре белән ята. Алар арасындагы чик Уржум сериясенең карбонат-балчык чыганакларын карбонат токымнары катламнары белән буялган ком-алевролито-балчык формалары аша уза.

Слобода ясалмалары, нигездә, балчык, алевролитлар, комлы ташлар, известьташлар һәм мергельләр белән тезелгән. 130-140 м абсолют билгеләрдән югарырак булган слобода утырмаларының катламы 45-50 м тәшкил итә.

Неоген плиоцен ятмалары каралган территориянең көнчыгышында таралыш алган. Тальвег палеоүзәннәре Зөя елгасы үзәненә параллель сузылган һәм Югары Казан асъярусы терриген-карбонат калынлыгы түбәсенә тоташкан. Палеоүзән тальвегы өстендә ком-балчык плиоцен утырмаларның катламы 30-46 м кадәр җитә.

Дүртенчел чордагы ятмалар тикшерелә торган территориядә киң таралуга ия, бары тик кайбер участокларда үзәнлекләрнең текә калкулыкларында гына юк. Ятмалар катламы 10-15 м.

Карала торган территория, гидрогеологик районлаштыру нигезендә, икенче тәртип буенча Идел-Сурск артезиан бассейны чикләрендә урнашкан. Су үткәрүчәнлегенең төре һәм зурлыгы буенча, суның характеры буенча, киселешнең өске өлешендә түбәндәге гидростратиграфик бүлекчәләр аерылып тора *(рәсем. 2,3)*:

- сулы неоген-дүртенчел аллювиаль комплекс ($N_2$-Q);
- локаль аз сулы слобода карбонат-терриген комплексы ($P_3$Sl);
- сулы Уржум терриген-карбонат комплексы ($P_2$ur);
- сулы Казан терриген-карбонат комплексы ($P_2$kz).

Махсус гидростратиграфия бүлекчәләре актив су алмашу зонасында урнашкан.

Бу зонада җир асты агымнары хәрәкәте Зөя һәм Идел елгаларының агызу йогынтысы астында. Җир асты суларын тукландыру атмосфера явым төшемнәре һәм зур үзәннәрнең сулык һәм

бортлары чикләрендә өске офыклардан аска түбән төшүче юлларны инфильтрацияләү хисабына башкарыла.

Җир асты суларын тукландыру атмосфера явым-төшемнәре һәм өске офыклардан Түбән җирләргә аска таба агып төшүче юлларны инфильтрацияләү хисабына башкарыла. Зур елгаларның үзәннәрендә Түбән Пермь су комплексларының җир асты суларын бушатуга бәйле басымның кире нисбәте күзәтелә.

*Сулы неоген- дүртенчел аллювиаль комплекс ($N_2$-Q)* комплекс плиоценның утырмаларына, шулай ук дүртенчел системаның неоплеистоцен бүлегенең югары звеносына һәм голоценның заманча утырмаларына туры килә. Ул палеоүзәндә һәм хәзерге Зөя елгасы үзәнлегендә һәм аның кушылдыкларында таралды.

Иң су үтемле токымнар булып төрле зурлыктагы таш белән бөртекле ком тора. Ятма шартлары буенча комплекс басымсыз диярлек, сирәк кенә җирле басым 1-15 м җитә. Грунт сулары көзгесе 53-54 м абсолют билгеләрдә урнашкан. Комплексның су хәрәкәте тигез түгел, бу су сыйдырышлыгының үзгәрүе, су сыйдырышлы ташларның литологик һәм гранулометрик составларының үзгәрүе белән бәйле. Скважиналарның чагыштырма дебитлары – тәүлегенә 0,07-2,5 л, ә фильтрлау коэффициентлары – тәүлегенә 1,2-30,7 м.

Комплекс суының химик составы 0,7-0,9 г/л кадәр минераллашкан чиста сулар, күбесенчә гидрокарбонат кальцийлы, гомуми катылыгы $10^0$Ж кадәр.

Комплексның туклану һәм таралу өлкәләре бер үк. Төп туклану атмосфера явым-төшемнәре һәм су басу суларын инфилтрацияләү хисабына башкарыла. Бушату- чишмә һәм елга үзәннәрендә. Комплекс дәрәҗәсе режимы елгалардагы су дәрәҗәсенә бәйле.




Масштаб 1:50 000

**2 нче рәсем. Схематик геологик-гидрогеологик карта**

*Шартлы билгеләр:*

*Гидрогеологик стратификация берәмлекләре*

$N_2$-Q - сулы неоген-дүртенчел аллювиаль комплекс ($N_2$-Q)

$P_3$sl - сүүткәрүчән локаль- сулы Слобода карбонат-терриген комплексы ($P_2$sl)

$P_2$ur - сулы Уржум терриген-карбонат комплексы ($P_2$ur)

скв.120

- суалу скважинасы, аның номеры . Суның химик төрен күрсәтүче төс
( - гидрокарбонат, - сульфат)

I——I геологик-гидрогеологик киселеш линиясе

чишмә

I
ЮЗ
а.о.,м

I
СВ

Масштаблар: горизонталь 1 : 50000
вертикаль     1 : 2 000

**3 рзсем . I-I линиясе буенча  схематик геологик-гидрогеологик киселеш**

Шартлы билгеләр:

*Гидростратиграфик бүленешләр:*




- неоген- дүртенчел аллювиаль су йөртү комплекс;
-үткәрүчән карбонат-терриген аз су йөртүчән комплекс ($P_2sl$);




- Уржум терриген-карбонат су йөртү комплексы ($P_2ur$);

- $P_2kz$ Казан терриген-карбонат су йөртү комплексы ($P_2kz$) Токымнарның литологик состав



Комсыл балчык Комташ Мергель

Балчык Известьташ Ком




К... дагы скважина. Өстәге сан –картадагы номеры. Буяу сынап
ка... тирәнлек интервалында химик су төренә туры килә. Кара ук
сь... ралган интервалдагы җир асты суларының басым зурлыгына
ту... ә.Ук янындагы сан- статик су дәрәҗәсенең абсолют билгесе;
с... ынау интервалыннан сан:  беренче -дебит л,/тәүл.,
и... - түбәнәю м;уңда катылыгы, $^0$Ж
С... мик тибы:
- г... бонатлы сул... ы




җир асты сулары дәрәҗәсе




2000-2003 елларда «Татарстан Республикасы чикләрендә Идел-Суръ һәм Кама-Нократ артезиан бассейннарының төче җир асты суларының ресурс потенциалын бәяләү һәм аны республика халкын су белән тәэмин итү чыганаклары белән тәэмин итү өчен локальләштерү темасы кысаларында, Зөя елгасы үзәнендә фаразлау ресурслары «С2» категориясе буенча тәүлеккә 31,794 мең м$^3$ күләмендә бәяләнгән төче җир асты суларының Зөя ятмасының Молвинск участогы ачыкланды. Участок мәйданы буенча чикләнгән структура — комлы аллювиаль неоген һәм дүртенчел утырмаларның локаль участогына туры китерелгән төче җир асты сулары ятмаларыннан гыйбарәт.

Норлаттагы җир асты байлыкларының тикшерелә торган участогы ятманың бу участогыннан көнбатыштарак 4,5 км ераклыкта, Зөя ятмасының Молвино участогындагы җир асты суларының эксплуатация запасларын булдыру өлкәсе чикләрендә урнашкан.

*Үткәрүчән локаль аз сулы Слобода  карбонат-терриген комплексы* районда иң югары гипсометрик позицияне били. Комплексның иң үткәрүчән токымнары-комлы ташлар, балчыклы ташлар арасында урнашкан мергель һәм известьташ катламнары. Комплексның

аскы өлешендә чишмәләр дебитлары 0,1-0,3 л/с артмый. Комплексны тукландыру атмосфера явым-төшемнәре хисабына башкарыла, бушату җирле гидрография челтәренә бара. Комплексның химик составы буенча гидрокарбонат магний-кальций яки катион составы буенча катнаш, минераллашуы – 0,3-0,4 г/л.

Комплекс тулысынча диярлек дренлашкан, шуның нәтиҗәсендә аның сулары хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү өчен чикле, нигездә чишмәләрне каптажлау юлы белән файдаланыла. Чишмәләрнең чыгуы 120-150 м абсолют билгеләрдә күзәтелә.

Уржум комплексының иң үтеп керә торган токымнары известьташлар, мергельләр, алевролитлар, комлы ташлар, кайвакыт доломитлар һәм ярыклы балчык төләре белән күрсәтелә. Уржум катламнары үсеш мәйданыны (Әрә елгасы үзәннәре һәм аның кушылдыклары бортларында) җир асты суларының чишмә рәвешендәге чыгулары 95-108 м абсолют билгеләрдә күзәтелә.

Уржум комплексының җир асты сулары, нигездә, басымлы, алар таралуның кырый зонасыннан тыш.

Җир асты сулары дәрәҗәсе, нигездә, 50 метрдан кимрәк тирәнлектә билгеләнә, ул вакыт-вакыт 78 метрга җитә.

Комплексны түбән ятмалардан җир асты сулары белән тукландыру тектоник зәгыйфьләнгән зоналарда, еш кына елга үзәннәре планында туры килә. Су тота торган токымнарның литологик составының бертөрле булмавы һәм свитаның ятма шартларының үзенчәлеге аның мәйданы буенча да, кисү буенча да төрле су хәрәкәтенә бәйле.

Гидрокарбонат һәм сульфат-гидрокарбонат магний-кальций составындагы минерализациясе 0,1-0,5 г/л булган төче сулар өстенлек итә, сирәгрәк гидрокарбонат-сульфатлы кальций-магний сулары минерализациясе 0,9 г/л булган, бу Казан терригенлы-карбонат комплексы белән үзара бәйләнешне күрсәтә.

Җир асты суларының туклану өлкәсе таралу мәйданына туры килә. Запасларны тулыландыру атмосфера явым-төшемнәренең инфильтрациясе һәм югарыда яткан катламнардан агып төшү исәбенә дә, шулай ук, түбән төзелешлеләрдән килгән подток исәбенә дә башкарыла, бу сульфатлар барлыкка килү белән раслана. Җир асты суларының коюы аларның елга үзәннәренә таба хәрәкәт итүләре юнәлешендә бара.

*Сулы Казан терриген-карбонат комплексы* карала торган район чикләрендә бөтен җирдә таралган. Иң суүткәрүчән токымнар каверноз известьташлар, сирәгрәк доломитлар комташлар тора.

Комплексның сулсыешлыгы тигез түгел, скважиналарның чагыштырма дебитлары 0,03 алып 1,2 л/с тәшкил итә. Су сыйдырышлы токымнарның төпсез ятмалары участокларында иң югары сулыкның булуы күзәтелә һәм ярылуның югары булуы зоналарына бәйле.

Комплексның җир асты суларын тукландыру югарырак һәм түбәнге сулы горизонтлардан агып чыгу исәбенә, шулай ук карала торган территориядән читтәге комплекс токымнары чыгу участокларында атмосфера явым-төшемнәрен инфильтрацияләү исәбенә гамәлгә ашырыла. Җир асты сулары агымы көнчыгышка, Зөя елгасы ягына юнәлгән.

Комплекс киселешендә вертикаль гидрогеохимик зональлек күзәтелә. Комплексның югары сулы горизонты сулары аеруча уңайлы сыйфат белән характерлана. Монда гомуми катгыйлык күләме буенча ($10^0$Ж кадәр) аз гына артып китүләр күзәтелә һәм, гомумән, су СанПиН 2.1.4.1074-01 "Эчә торган су" таләпләренә туры килә. Комплексның түбән сулы горизонтында суның сыйфаты начараю күзәтелә, минераллашу арта, гомуми катылык ($18^0$Ж артык), сульфатлар (500 мг/л артык).

## 3. Су алу корылмасына һәм продуктив сулык горизонтына характеристика

Норлат торак пунктында №120(РЭС) су алу корылмасы Казан терриген – карбонат комплексын эксплуатацияләүгә җиһазландырылган бер скважинадан тора. Су Норлат торак пункты халкының хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Скважинадан су алу елга 39,055мең $м^3$ тәшкил итә. Скважина ел әйләнәсендә автоматик режимда эшли.

1988 елда 98 м тирәнлектә бораулаган №120(РЭС) скважинасы Булатка елгаарасы (Зөя елгасының сул кушылдыгы) һәм аның уң як исемсез кушылдыгы, Норлат торак пунктыннан көньяк-көнбатыш читендә урнашкан. Скважина тамагының абсолют билгесе 116м.

Җир асты суларының статик дәрәҗәсе җир өслегеннән 60 м тирәнлектә билгеләнә, бу 56 м абсолют билгегә туры килә. Продуктив сулы горизонт 76-98 м тирәнлек интервалында (абсолют түбә һәм табан билгеләре 40 һәм 18 м) – ком ташлары катламнары белән ярыклы известьташлар. Сулы горизонт басымлы, түбә өслегеннән су басымы 16 м тәшкил итә. Скважинаның дебиты – тәүлеккә 3,0 л, түбәнәю – 6 м. Сулы горизонт аз үткәрүчән токымнар катламы белән каплана (дүртенчел комташлар, Уржум һәм Казан балчыклары,гомуми катламы 15 м артык). Күрсәтелгән су алуда (1,23 л/с) исәпләнгән динамик дәрәҗә 62,5 м (түбәнәйтү 2,5 м артык түгел) тәшкил итәчәк.

Скважина түбәндәге конструкциягә ия: 219мм диаметрлы обсад колонна 0,5 дән 65м га кадәр интервалда урнаштырылган; 168мм диаметрлы обсадная колоннасы 62 дән 98 м кадәр интервалда урнаштырылган, фильтрның эш өлеше 78-98 м интервалында урнаштырылган.

Сулы горизонт аз үткәрүчән токымнар катламы белән каплана (дүртенчел комташлар, Уржум һәм Казан балчыклары, гомуми катламы 15 м). Продуктив су йөртүчән горизонт белән өске сулыклар арасында гидравлик бәйләнеш юк.

Су алу корылмасының туклану өлкәсендә Казан продуктив комплексының тоташ су үткәрми торган түбәсе бар һәм һәркайда аз үткәрүчән токымнар (дүртенчел комташлар, Уржум һәм Казан балчыклары) белән капланган һәм ул өслектән пычранудан яхшы сакланган.

Скважиналарның төп характеристикалары 1 нче таблицада һәм геологик-техник киселештә китерелгән (4 нче рәсем).

## 4. ССЗ пояслары чикләрен гидрогеологик нигезләү

СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә, хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су коймалары өч пояс составында оештырыла торган санитария саклау зоналары (ССзның) белән тәэмин ителергә тиеш:

